**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 17 февраль

№ 101

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

исемлеккә түбәндәге эчтәлекле 31 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «31 | 2016 – 2020 елларга Татар- | Татарстан Республикасы | Татарстан Республикасы | Балыкчылык хуҗалыкларының продуктивлыгын |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | стан Республикасында товарлы аквакультураны (товарлы балыкчылыкны) үстерү | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасының балыкчылык хуҗалыклары (килешү буенча) | күтәрү, аквакультураны үстерүне стимуллаштыру юлы белән республиканың су объектларында ресурс-чимал базасын торгызу һәм саклау;<br>балыкчылык хуҗалыкларының җитештерү объектларын һәм инфраструктурасын техник һәм технологик модернизацияләү;<br>техник сәбәпләр буенча файдаланылмый торган буаларда балыкчылык хуҗалыгы мелиорациясен үткәрү һәм аларны кулланылышка кертү;<br>яңа балык питомниклары төзү һәм булганнарны төзекләндерү;<br>товар балыгын (карп һәм балыкларның үсемлек ашаучы төрләре) үстерү өчен буалар төзү һәм (яки) төзекләндерү;<br>мәрсин балыгының һәм сөләйман балыгының (ала балык) товар балыкчылыгы индустриаль объектларын төзү, төзекләндерү;<br>балыкчылык хуҗалыкларында ветеринария-санитария, эпизоотиягә каршы, дәвалау-профилактика чаралары үткәрү;<br>аквакультура өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләре үткәрү;<br>балыкчылык хуҗалыкларын кадрлар белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме буенча чаралар үткәрү;<br>балыкчылык хуҗалык- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ларын мәгълүмат белән тәэмин итү системасын үстерү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\101.docx